Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советы

**КАРАР № XXIX-5**

Балык Бистәсе штп. 2018 елның 19 феврале

Россия Эчке эшләр министрлыгының Балык Бистәсе районы буенча бүлегенең җәмәгать тәртибен саклауны тәэмин итү, гражданнарның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен җинаятьчел кул сузулардан яклау буенча эшен оештыру, җәмәгатьчелек ышанычын тәэмин итү һәм гражданнарга ярдәм итү буенча күреләә торган чаралар турында

Россия Эчке эшләр министрлыгының Балык Бистәсе районы буенча бүлеге башлыгы Н.Ф.Мостафинның Балык Бистәсе районы буенча бүлегенең җәмәгать тәртибен саклауны тәэмин итү, гражданнарның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен җинаятьчел кул сузулардан яклау буенча эшен оештыру, җәмәгатьчелек ышанычын тәэмин итү һәм гражданнарга ярдәм итү буенча күреләә торган чаралар турындагы эшен оештыру турындагы мәгълүматын тыңлап фикер алышканнан соң Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы КАРАР БИРӘ:

1. Россия Эчке эшләр министрлыгының Балык Бистәсе районы буенча бүлегенең җәмәгать тәртибен саклауны тәэмин итү, гражданнарның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен җинаятьчел кул сузулардан яклау буенча эшен оештыру, җәмәгатьчелек ышанычын тәэмин итү һәм гражданнарга ярдәм итү буенча күреләә торган чаралар турындагы эшен оештыру турындагы мәгълүматын игътибарга алырга.

2. Россия Эчке эшләр министрлыгының Балык Бистәсе районы буенча бүлеге башлыгы Н.Ф.Мостафинга тәкъдим итәргә:

2.1) экстремистик эшчәнлекне кисәтү буенча оператив-эзләү чараларын үткәрүне дәвам итәргә;

2.2) максатчан кулланмауга һәм бюджет акчаларын урлауга бәйле җинаятьләргә каршы көрәш бурычларын өстенлекле тәртиптә хәл итүне дәвам итәргә, торак-коммуналь хуҗалык объектларын, шулай ук торак милекчеләре ширкәтләре һәм идарәче компанияләр счетларында булган торак-коммуналь хуҗалык объектларын модернизацияләүгә һәм аларның эшчәнлеген тәэмин итүгә бүлеп бирелә торган акчаларның сакланышын тәэмин итүгә көчне тупларга;

2.3) наркотикларның һәм коралның законсыз әйләнешен оештыруга катнашы булган затларга карата оператив-эзләү чараларын үткәрүне дәвам итәргә;

2.4) элек туктатылган җинаятьләрне ачу буенча эшне, шул исәптән эзләү буенча да, дәвам итәргә;

2.5) балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын, гаилә иминлеген, ятимлекне кисәтү, аларның законлы мәнфәгатьләрендә хокукларын яклау буенча эшне активлаштырырга;

2.6) юл хәрәкәте кагыйдәләрен бозуның аерым төрләрен төркемнәр тарафыннан эшләүне тәэмин итүгә юнәлдерелгән чаралар комплексын тормышка ашыру, юл-патруль хезмәте нарядларының авыр хәлдә булган урыннарда эшен оештыру, беренче чиратта машина йөртүчеләрнең исерек хәлдә булулары белән бәйле.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык  Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне законлылык, хокук тәртибе, муниципаль милек һәм җирле үзидарә буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балык  Бистәсе муниципаль
район Советы рәисе
урынбасары И.Г.Ибраһимов